| | |
|---|---|
| **СОВЕТ УРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**"29" ноябрь 2021 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Урыс торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 24 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:"Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?,Россия Армиясе сафларына чакырылган, 1 төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардандан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1. Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю), Мәктәп ур. 1, һәм Дуслык ур. 66 нчы йортларны тоташтыручы, (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

2. Урыс торак пунктында чаралар оештыру һәм бәйрәмнәр үткәрү (бүләкләр алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Урыс торак пунктында юлларны грейдрлау, кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4. Урыс торак пунктында җәйге чорда юл кырыйларын чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5.Урыс торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүплекләрне буртлау, чүп чыгару, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6.Урыс торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

7.Урыс торак пунктында су алу скважинасына тирән насос сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә, җыенда сайлау хокукына ия булган 172 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен җыенда 92 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучылар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Урыс торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип таныrга.

2.Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү буенча карарны кабул итергә,Россия Армиясе сафларына чакырылган, 1 төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардандан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1.Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю), Мәктәп ур. 1, һәм Дуслык ур. 66 нчы йортларны тоташтыручы, (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2. Урыс торак пунктында чаралар оештыру һәм бәйрәмнәр үткәрү (бүләкләр алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Урыс торак пунктында юлларны грейдрлау, кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4. Урыс торак пунктында җәйге чорда юл кырыйларын чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5.Урыс торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүплекләрне буртлау, чүп чыгару, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6.Урыс торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

7.Урыссу торак пунктында су алу скважинасына (су башнясы) тирән насос сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү) кабул ителгән.

3.Җыен нәтиҗәләрен Урыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http://menzelinsk.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan. кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге башлыгына җибәрергә

Халык җыенында рәислек итүче,
Урыс авыл җирлеге башлыгы

_____________ (имза)

И. С.Аксюкова
(имзаның аңлатмасы)